**СОВЕТ ТУБЫЛГЫТАУСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул.Молодежная, д.73,
с. Тубылгы тау,423181

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТУБЫЛГЫТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Яшьләр урамы, 73
Тубылгы Тау авылы,423181

тел.: (8-84348) 3-82-58, факс: (8-84348) 3-82-44, Tub.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2016 елның «15» нче январе № 6-16

РЕФЕРЕНДУМ ҮТКӘРҮ ИНИЦИАТИВАСЫ ТУРЫНДА

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы Татарстан Республикасы законынын 17, 18 статьялары, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге Советы

КАРА ИТТЕ:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрүне инициативлаштырырга:

«Сез 2016 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Тубылгы Тау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедэн, көндезге уку формасында укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тол хатыннары, 1 төркем инвалидлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен ризамы:

- Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау Тубылгы Тау авыл җирлеге чикләрендә юлларны карап тоту һәм норматив хәлгә китерүгә 145 000 сум (йөз кырык биш мең сум);

- Көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны вакытлыча ташлау өчен урыннарны төзекләндерү һәм саклау. Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге чикләрендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чар җыюны һәм чыгаруны оештыру 40 000 сум (кырык мең сум);

- Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлегенең авыл эчендәге юлларында шлагбаумнар ясау һәм урнаштыру 15 000 сум (унбиш мең сум).

ЭЙЕ ЮК».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» нда «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Тубылгы Тау авыл җирлеге территориясендә махсус

мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

3. Бу карар бастырылган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Тубылгы Тау авыл җирлеге башлыгы

Ф.Ф. Исмәгыйлев